**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Бигеш авыл җирлегенең Кәрәкәс торак пунктында**
**2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**
**гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

**13 ноябрь 2025 ел** **№ 1**

"Иҗтимагый хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 20.03.2025 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге Кәрәкәс торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциясендә катнашучылардан, аларның гаилә členнарыннан һәм махсус хәрби операциядә һәлак булганнарның гаиләләреннән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең Керекес авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2026 елда үзара салымны 600 (алты йөз) сум күләмендә билгеләргә.

2. - Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (зиратка юл салу).

3. Карарны кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә (Бигеш авыл җирлеге Уставының 69 ст. 5п.) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Зәй муниципаль районы**
**Бигеш авыл җирлеге башлыгы** ____________ **И.Р. Вәлиев**